ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 11 » август **2021 ел** **№ 575**

**Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

“Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында” Арча район Советының 2019 елның 18 апрелендәге 246 номерлы карары нигезендә һәм документларны карау һәм мемориаль такта кую мөмкинлеге турында карар кабул итү максатыннан, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую комиссиясе турында Нигезләмәне;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую комиссиясе составын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Т. Мөхәммәтшинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
"11" август 2021 ел, №575
карары белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МЕМОРИАЛЬ ТАКТАЛАР КУЮ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую комиссиясе (алга таба - Комиссия) Арча муниципаль районында даими эшләүче комиссия булып тора.

1.2 Үз эшчәнлегендә Комиссия "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 01 апрелендәге 163 номерлы карары, әлеге Нигезләмәгә һәм башка хокукый актларга таяна.

## 2. КОМИССИЯНЕҢ МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Комиссия Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую турындагы тәкъдимнәрне карау максатыннан төзелә.

2.2. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- тәкъдимнәрне тулысынча, үз вакытында, объектив карау;
- Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую мөмкинлеге һәм максатка ярашлылыгы турында карар кабул итү.

## 3. КОМИССИЯНЕҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

3.1. Комиссиянең хокуклары:

- Комиссиягә карау өчен кирәкле Арча муниципаль районында мемориаль такталар урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәдә күрсәтелгән материалларны һәм документларны мемориаль такталар кую инициаторларыннан соратып алырга;
- Комиссия утырышына кызыксынучы затларны, экспертларны, белгечләрне, шул исәптән тарихчыларны, архитекторларны, туган якны өйрәнүчеләрне, башка белгечләрне, җәмәгатьчелек вәкилләрен чакырырга;
- Арча муниципаль районының дәүләт хакимияте органнарыннан, учреждениеләрдән һәм җирле үзидарә органнарыннан Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга.

3.2. Комиссия түбәндәгеләргә бурычлы:

- эшчәнлекне Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә гамәлгә ашырырга;

- Комиссия карарларын беркетмә белән рәсмиләштерергә.

## 4. КОМИССИЯНЕ ФОРМАЛАШТЫРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ АНЫҢ СОСТАВЫ

4.1. Комиссиянең персональ һәм санлы составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

4.2. Комиссия составына Комиссия рәисе, рәис урынбасары, Комиссия секретаре, Комиссия әгъзалары керә.

4.3 Комиссия составына Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Арча район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясе вәкилләре (килешү буенча), Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ, территориясендә мемориаль такта кую тәкъдим ителә торган авыл яки шәһәр җирлеге башлыгы (килешү буенча), иҗади һәм иҗтимагый оешмалар керә. Кирәк булганда, Комиссия үз эшенә төрле оешмалар һәм ведомстволар белгечләрен җәлеп итәргә мөмкин.

4.4. Комиссиянең барлык әгъзалары да үз вәкаләтләрен иҗтимагый башлангычларда башкаралар.

## 5. КОМИССИЯ УТЫРЫШЛАРЫ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

5.1. Комиссия утырышлары тәкъдимнәр кергән саен уздырыла.

5.2. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларның яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

5.3. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- бирелгән тәкъдимнәрне һәм аларга бирелгән документларны карый;

- Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую тәртибе турындагы Нигезләмә таләпләре нигезендә тәкъдимнәрнең һәм аларга кушып бирелә торган документларның тулылыгын һәм тиешенчә рәсмиләштерелүен тикшерә.

5.4. Комиссия карарлары Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан гади күпчелеге тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

5.5. Комиссия утырышлары карарлары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, Комиссия беркетмәсен секретарь алып бара. Беркетмәне рәсмиләштерүгә ун көн бирелә.

5.6. Комиссиянең утырышлар беркетмәләренә Комиссия рәисе һәм Комиссия секретаре имза куя.

5.7. Комиссия кергән документларны карый һәм документлар кергән көннән алып бер ай эчендә мемориаль такта кую мөмкинлеге турында карар кабул итә.

5.8. Комиссия мемориаль такта кую турында уңай карар кабул иткән

очракта, Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер ай вакыт эчендә Арча муниципаль районы башкарма комитетына тиешле карар проектын тапшыра.

Проектка кушымта итеп бирелә:

Комиссия утырышы беркетмәсе яисә беркетмәдән өземтә;

мәңгеләштерелә торган вакыйга яисә зат турында гомуми белешмәләр;

мемориаль такта кую күздә тотылган урын турында мәгълүмат;

мемориаль тактаны проектлау, әзерләү һәм билгеләү эшләрен финанслау чыганаклары турында белешмәләр;

территориясендә мемориаль такта урнаштыру тәкъдим ителә торган авыл, шәһәр җирлекләре башлыгы белән килештерү.

Арча муниципаль районы башкарма комитетының мемориаль такта кую турындагы карары Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Комиссия тарафыннан тискәре карар кабул ителгән очракта, инициаторга бу хакта мондый карар кабул ителгән көннән 15 көн эчендә хәбәр ителә.

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
"11" октябрь 2021 ел, №575
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Мөхәрәмов Рәсүл Ринатович | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Мөхәмәтшина Алинә Таһировна | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Бәхтиярова Гөлүсә Сәлимҗановна | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” МУ баш белгече, комиссия секретаре |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Әюпов Илфар Илдарович | -Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ башлыгы; |
| Мөхәмәдияров Рамил Данилович | -Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы; |
| Габдулгазизов Ильяс Нурсилович | -Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Нурмөхәмматова Рузия Илсуровна | -Арча район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясе әгъзасы (килешү буенча); |
| Заһидуллина Гөлнара Наилевна | -Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару бүлеге башлыгы; |
| Һидиятов Ринат Әлифханович | - Арча муниципаль районы Иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча); |
| Хәмидуллина Рәмзия Шәриповна | - Арча муниципаль районы ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча); |

-территориясендә мемориаль такта урнаштыру күздә тотыла торган җирлек башлыклары (килешү буенча).

Җитәкче Р.Р. Мөхәрәмов